**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**«ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«17» октябрь 2016 ел                                                                                    № 9/4

**Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшен яктыртучы массакүләм мәгълүмат чараларын аккредитацияләү тәртибе турында нигезләмә һәм Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү комиссиясе турында нигезләмә хакында**

Тукай муниципаль районында яшәүчеләргә җирле үзидарә органнары эше турында тулырак мәгълүмат бирү максатыннан, «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» РФ Законының 48 статьясы нигезендә, Тукай муниципаль районы уставына таянып, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшен яктыртучы массакүләм мәгълүмат чараларын аккредитацияләү тәртибе турында нигезләмәне 1 кушымта нигезендә расларга.
2. Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү комиссиясе турында нигезләмәне 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Тукай районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары                                                Р.И. Закиров